

Рузаевка районынын Шишкеево авылында дvртенче тапкыр «Наурские щи» казак мәдәнияте фестивале горләп vтте.
Чара ботен Мордовиядән һәм хәтта башка тобәкләрдән килгән кунакларны бәйрәм белән соендерде. Традиция буенча катнашучылар «Троицкое» Саранск Казак хуторы җәмгыяте казаклары, Мордовиянен вокаль һәм бию коллективлары, халык кәсебе һәм декоратив-гамәли иҗат осталары булды. - “Наурские щи” – Казачкалар коне. Тарихы шулайрак: кайчандыр Кавказда Наурская станицасы булган, аннан барлык ир-атлар сугышка киткән, бары тик хатын-кызлар, картлар һәм балалар гына калган. Шул вакыт станицага тау кешеләре һожvм итә башлаган. Шуна барлык хатын-кызлар vз жирләрен якларга баса. Корал сыйфатында кайнап торган сумала кулланылган: аны алар камап алган дошманнарнын башларына тvккәннәр, ә ул беткәч, кайнап торган щи эшкә жигелгән. Терски казаклары батырларча саклананалар, алар кулыннан бик кvп тау кешеләре һәлак була, әмма кочләр тигез булмый. Куркусыз сакчылар сонгы сугышка хәзерләнгән чакта ярдәм килеп житә. Шуннан бирле “Наурские щи” бер яктан кыюлык синонимына әверелсщ, икенче яктан - хурлык символына әверелде, чонки станицаны саклаучылар саныннан остен булган тәжрибәле сугышчылар сугышта казак хатыннарын жинә алмыйлар,- дип искә тошерде бәйрәм тарихын “Троицкое” Саранск казак хуторы җәмгыяте атаманы урынбасары Роман Бородин.
Фестиваль vткән зур мәйданчыкта халык кәсебе товарларын сайлап алырга мцмкин булган торле урыннар: Тvбән Новгород осталары тарафыннан кулдан эшләнгән музыкаль сувенирлар, Старошайгово районы осталарыныж керамикадан эшләнгән әйберләр саттылар, Пензяклар конбагыш козинаклары тәкъдим иттеләр.
Теләге булган һәркем салам курчаклар vрv буенча мастер-класска йори алган.
Фестивальдә катнашучыларда «Троицкое» Са-ранск казак хуторы җәмгыятенен мавыктыргыч мастер-классы аеруча кызыксыну уяткан.
Бәйрәм азагында барлык кунакларны борынгы рецепт буенча пешерелгән щи белән сыйлаганнар.